12+

# DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ

Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы **27** май, **2016** ел № 3 (148)



# «Киләчәк фәне – яшьләр фәне»

Альфред Шакиров фотосы

Май азагында Казан федераль университетында үткәрелә торган матур традиция бар – КФУ студентлары арасында иң яхшы фәнни эш бәйгесе нәтиҗәләренә йомгак ясау тантанасы. Җиңүчеләр сентябрьдә «Киләчәк фәне – яшьләр фәне» икенче фәнни яшьләр форумы кысаларында үтәчәк Бөтенрәсәй студентларының һәм аспирантларының фәнни-тикшерену эшләр конкурсында катнашачаклар.



## «ТУРЫДАН-ТУРЫ ЭЛЕМТӘ»

Бүген, 27 майда, «Универсмотри» телеканалында 14.00 сәгатьтә КФУ ректоры **Илшат Гафуров** белән «Турыдан-туры элемтә» оештырыла. Күрми калма!



## КОТЛЫЙБЫЗ!

24 май көнне күренекле галим, КФУның шәрәфле профессоры, тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының элеккеге рәисе Индус Ризак улы Таһировка 80 яшь тулды.




## ЖУРНАЛИСТИКА МӘКТӘБЕ

В.Мезенцев исемендәге журналистика мәктәбе, Россия Журналистлар Берлеге һәм МГУ, МГИМОның журналистика факультетлары «Юные журналисты России» дип исемләнгән **махсус бәйге** уздыра! Бәйгедә 20 яшькә кадәр булган һәм журналистика белән шөгыльләнгән һәркем катнаша ала! Материалларны 2016 нчы елның 31 нче октябренә кадәр җибәрергә мөмкин.

**Раил САДРЕТДИНОВ**

ЭЛЕК КФУ СТУДЕНТЛАРЫ АРАСЫНДА ИҢ ЯХШЫ ФӘННИ ЭШ БӘЙГЕСЕ НӘТИҖӘЛӘРЕНӘ ЙОМГАК ЯСАУ ТАНТАНАСЫ КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ АКТЛАР ЗАЛЫНДА УТСӘ, БЫЕЛ А.М.БУТЛЕРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ХИМИЯ ИНСТИТУТЫНДА БУЛДЫ.



# КФУда ЯШЬЛӘР ФӘНЕ

КФУ студентлары арасында иң яхшы фәнни эш бәйгесе өч турда үткәрелә. 2016 елда беренче тур нәтиҗәләре буенча 17 институттан һәм факультеттан жюри хозурына 168 эш тәкъдим ителгән. Икенче турда жюри үз эшен 3 юнәлештә: табигый фәннәр, инженер-техник, социогуманитар фәннәр секцияләрендә дәвам иттерә. Өченче турга табигый һәм инженер-техник юнәлеш буенча 28, ә социогуманитар фән юнәлеше буенча 15 эш үтә һәм аларның барысы да диярлек жюриның югары бәясен ала. Конкурс нәтиҗәләре буенча җыентык бастырып чыгару күздә тотыла.

Студентларны сәламләп, КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры **Данис Нургалеев**: *«168 эш — бик күп һәм күңелле. Бу Казан университетында яшь галимнәр кимемәгәнлеген, Казан фәнни мәктәбенең көчен күрсәтеп тора. Галим һөнәре — дөньяда иң яхшы һөнәрләрнең берсе ул. Беренчедән, сез үз кызыксынуыгызны дәүләт акчасы хисабына канәгатьләндерәсез, икенчедән, үз-үзегез белән гармониядә яшисез, башкалар белмәгәнне беренчеләрдән булып беләсез — иң кызыгы да шул бит»*, — диде.

Социогуманитар фәннәр юнәлеше буенча жюри рәисе, Психология һәм белем бирү институтының шәхес психологиясе кафедрасы мөдире **Леонид Попов**, һәр катнашучының эшенә бәя биреп, анализ ясады. *«Ике көн буе Мәгариф буенча халыкара форум кысаларында Германия, Ирландия, Шотландия, АКШтан килгән катнашучылардан аларда студентлар фәне ничек оештырылуы турында докладлар тыңладым һәм без дөрес юнәлештә дигән нәтиҗәгә килдем. КФУ — көчле белем бирү һәм фәнни үзәк, биредә студентларның фән белән шөгыльләнүенә тиешле урын бирелә»*, — диде Л.Попов үз чыгышында.

Табигый фәннәр юнәлеше буенча жюри рәисе, Фундаменталь медицина һәм биология институтының биоэкология кафедрасы мөдире **Илгизәр Рәхимов** билгеләп үткәнчә, бу конкурс һәр елдагыча үзенчәлекле: табигый фәннәр буенча эшләрнең дәрәҗәсе бик югары һәм иң яхшыларын билгеләү авыр булган. *«Беренчедән, күп эшләр фәнара характерда. Элек, мәсәлән, химия буенча эш килсә — аны һичшиксез химиклар эшли иде. Ә хәзер төгәл генә моны әйтүе кыен. Фәннәрнең үрелеп баруы — перспектив юнәлеш. Икенчедән, барлык структур бүлекләрнең активлыгы. Күп еллар буенча табигый фәннәр буенча лидер булып Физика институты торды. Быел Экология һәм табигый байлыклардан файдалану институты, Геология һәм нефть-газ технологияләре институты лидерлар рәтендә»*.

* * *

Психология һәм белем бирү институты студенты, социогуманитар фән юнәлешендә җиңүче **Надежда Сәйфуллина** КФУда уку дәверендә инвалид балаларны лекотекада



(үсешләрендә катлаулы тайпылышлардан коткаруга багышланган махсус хезмәт, структур бүлек) эшләүче укытучы-логопед өчен махсус программа төзегән. ТРда бүген бары тик 2 лекотека бар. *«Без, мондый балалар белән эшләгәндә, музыка әсәрләрен кулланырга тәкъдим итәбез. Музыка, А.Ухтомский теориясе буенча, баш миенең үлгән күзәнәкләре барлыкка китергән бушлыкны тутыра ала. Аның уңай тәэсире инде дәлилләнгән. Шулай итеп, һәр логопед безнең программадан файдалана ала, ул Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандартларына тулысынча җавап бирә. Сүз уңаеннан, без аны үзебез дә сынап карадык, нәтиҗәләре шаккатыра»*, — дип бүлеште ул.

* * *

Табигатый һәм инженер-техник фәннәр юнәлешендә җиңүче, Физика институты магистранты **Илнур Фарухшин** беренче фәнни адымнарын 3 нче курста укыганда ясаган икән. *«Минем эшем ультрафиолет нурланыш табуга багышланган. Аның ярдәмендә материалларны югарырак төгәллек белән эшкәртеп булачак. Әлегә нурланышны алдык, алга таба аны материалларны эшкәртүдә кулланырга җыенабыз. Һичшиксез, киләчәктә без эшләгән фәнни хезмәт сәнәгатьтә кулланылыр дип уйлыйбыз. Чөнки бүген югары төгәллек белән эшкәртү алымы катлаулы, ә безнеке гади»*.

***P.S:*** Финалга чыккан барлык катнашучыларга һәм аларның фәнни җитәкчеләренә акчалата бүләк каралган.

# ИСТӘЛЕК ТАКТАСЫ – ИСӘННӘР ӨЧЕН

**Васил ГАРИФУЛЛИН,** татар журналистикасы кафедрасы мөдире

19 МАЙДА, ТАТАРСТАН МАТБУГАТЫ КӨНЕНДӘ, КҮРЕНЕКЛЕ ПЕДАГОГ ҺӘМ ГАЛИМ, ЖУРНАЛИСТИКА ФАКУЛЬТЕТЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ДЕКАНЫ **ФЛОРИД ӘГЪЗАМОВ** ИСТӘЛЕГЕНӘ УЛ ЯШӘГӘН ЙОРТ ДИВАРЫНДА МЕМОРИАЛЬ ТАКТА АЧЫЛДЫ.





Руслан Бушков фотолары

Без аның белән көн саен күзгә-күз очрашып торабыз: минем эш бүлмәмдә иң түрдәге урыннарның берсендә аның рәсеме тора. Миңа төбәлгән карашында җылылык тоям, кайвакыт шелтә дә сизгән кебек булам. Бүлмәгә кергән студентлар аның кем булуы турында сораштыралар. Кызганыч, Казан университеты тарихында үзенең тирән эзен калдырган бу шәхес турында бүгенге студентлар ул язып калдырган китаплар, аның турындагы истәлекләр аша гына беләләр. Ә миңа беренче курстан башлап аның шәкерте, соңрак хезмәттәше, теләктәше һәм хәтта берара җитәкчесе дә булырга туры килде...

Гаҗәп кеше иде ул Флорид Әгъзамов! Үзе гаять тирән белемле, зыялы, үзе гади һәм тыйнак. Кыюсыз гына университет бусагасын атлап кергән дистәләрчә татар балаларының беренче булышчысы, ярым ятим нәүмизләрнең килеп сыеныр кешесе була белде ул. Аның әнә шундый киң күңелле, олы җанлы гуманист шәхес булып формалашуы үз тормыш юлының сикәлтәләре белән дә бәйле булгандыр.

Кече яшьтән атаклы шагыйрь булырга хыялланган Флорид, мәктәпне медальгә тәмамлап, зур өметләр белән татар әдәбиятының Мәккәсе булган Казанга юл ала. Аны монда да тормышның авыр зынҗыры көтеп тора икән. Университетның татар бүлегенә укырга кергән егет студентлар тормышының ачлы-туклы бөтен михнәтләрен башыннан кичерә. Диплом алгач, укуда аеруча өлгергәннәрне, каләм тибрәткәннәрне газета-журналларга эшкә җибәрәләр. Флорид Питрәч районына барып эләгә. Шул вакыттан башлап, Ф.И.Әгъзамовның бөтен гомере журналистика белән бәйләнә. Аның сәләтен, тырышлыгын күреп, тиздән «Социалистик Татарстан»га эшкә чакырып алалар. 1968 елда ул Мәскәүдә журналистика буенча аспирантурага керә. Диссертация яклап Казанга кайткач, янә «Социалистик Татарстан» мөхәрриренең урынбасары, янә әдәбият-сәнгать, мәдәният дөньясы...

*Журналистика – илдәге хәлләрне яхшы якка үзгәртергә сәләтле көч.*

Пол Хлебников.

Күп тә үтми, аңа Казан дәүләт университетында яңа гына оешкан журналистика кафедрасын җитәкләргә тәкъдим итәләр. Шулай итеп, Ф.Әгъзамов Идел буе төбәге өчен журналист кадрлар әзерләүче үзәкне аякка бастыру һәм ныгыту эшенә керешә. Кафедрага җитәкчелек итү белән бергә, университетның филология факультеты деканы итеп тә сайлана. Бу елларда Ф.Әгъзамов журналистика бүлеген факультет итү, татар журналистикасы кафедрасы ачу идеясен тормышка ашыра, факультетның беренче деканы, кафедраның беренче мөдире була. Ул Татарстанда журналистика фәнен үстерүгә зур өлеш кертә. Шул ук вакытта милли кадрлар әзерләүдә, укытыла торган барлык курсларны татарчалаштыру, туган телебездә уку ярдәмлекләре һәм программалары булдыру юнәлешендә шактый эш башкара, укытуның әчтәлеген заманча итәргә тырыша. Бүгенге милли мәгълүмат кыры тулаем ул әзерләгән кадрлар кулында дисәк, ялгышмабыздыр.

Флорид ага, журналистика теоретигы булып кына калмыйча, гомере буе публицистик мәкаләләр белән чыгыш ясады. Тәрҗемә өлкәсендәге нәтиҗәле хезмәтләре өчен республика журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге бүләгенә лаек булды. Тынгысыз туксанынчы елларда үткен каләме белән танылган фельетончыга да әйләнеп куйды ул. Студентлар газетасы буларак үзе үк оештырган «Мәгърифәт» газетасында бүлек мөдире булып эшләде, аннары «Татарстан» журналы хезмәткәре, редколлегия әгъзасы буларак, әлеге басмаларны үстерүгә үзеннән зур өлеш кертте.

Татарда очерк жанрының үсешенә багышланган гаять тә кызыклы китабына Флорид Әгъзамов «Үзәктә – кеше» дип исем куйган иде. Моның белән ул журналистикабызның үзәгендә кеше, шәхес торырга тиешлеген ассызыклады. Үзенең тормышы, яшәү рәвеше белән дә Флорид Әгъзамов бу бөек принципка тугры булды. Булачак каләм ияләрен беренче чиратта үзенең шәхси үрнәге, сирәк очрый торган киң күңеллелек, кешелеклелек сыйфатлары белән тәрбияләгән бу олпат затның исеме, һичшиксез, Татарстан журналистикасы тарихына алтын хәрефләр белән инде язып куелды! Бүген бу исемне без ташка уеп та мәңгеләштердек. Истәлек тактасы – ул, беренче чиратта, исәннәр өчен, алар буыннар истәлеген лаеклы сакласыннар өчен. Университеттагы бер генә доцентка да (ә Флорид ага доцент вазыйфасында иде) Татарстанда мондый такта куя алганнары юк. Милләткә үзен аямыйча хезмәт итеп (дөньяда бердәнбер булган татар журналистикасы кафедрасы булдырып, мөстәкыйль татар журналистикасы факультетын гамәлгә куеп, беренчеләрдән булып бөек Тукайның журналист булуын дөньяга танытып, Тукай бүләге алган өч язучыны тәрбияләп, татар дөньясына моннан тыш йөзләрчә талантлы журналист әзерләп һ.б., һ.б.), мондый хөрмәт билгесенә ул күптән лаек иде!

Истәлек тактасында аның йөзе горельеф рәвешендә бронзага уеп ясалган. Шул ук мөлаем, уйчан караш... Шул ук моңсу күзләр... «Сезне сагынам, шәкертләрем, дусларым!» – дип дәшә сыман. Без дә аны сагынабыз...




# КФУның «РОССИЯ СТУДЕНТЛАР ЯЗЫ»нда ҖИҢҮГӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ

**Раил САДРЕТДИНОВ**

КАЗАН БЫЕЛ 3 НЧЕ ТАПКЫР БӨТЕН РӘСӘЙ БУЕНЧА ИҢ ТАЛАНТЛЫ, ҖЫР-БИЮГӘ, НӘФИС СҮЗГӘ ОСТА СТУДЕНТЛАРНЫҢ ҖЫЕЛУ, ОЧРАШУ УРЫНЫНА ӘВЕРЕЛДЕ.

Шәһәребездә 15-19 нчы май көннәрендә гөрләп «Россия студентлар язы» фестивале үтте. КФУ студентлары да әлеге яз, иҗат, яшьлек бәйрәмен зарыгып көтеп алды. Чөнки Казан федераль университеты «Республика студентлар язы» фестиваленең гран-при иясе иде.

«Россия студентлар язы – 2016» фестивалендә Казан данын яклап КФУдан 40ка якын студент төрле номинацияләрдә, төрле иҗади коллективларда чыгыш ясады. Моннан тыш студентларыбыз оештыру эшләрендә дә катнаштылар: килгән кунакларны озатып йөрделәр, конкурс мәйданчыклары өчен җаваплы булып тордылар. Барысын да исәпкә алсаң, КФУдан барлыгы 100дән артык кеше «Россия студентлар язы»нда хезмәт куйды. Университетыбызның «Театрон» иҗат остаханәсе (җитәкчесе Л.Әхмәтҗанова), «Bridge» вокал коллективы, Никита Савельев һәм «Журналистика» номинациясендә Аскар Галимов фестивальнең конкурс программасында катнашса, «Казаным» ансамбле һәм «Art-works» бию коллективы фестивальнең Казан университеты янәшәсендә үткән ачылыш тантанасында тамашачыларның күңелен күрде. Моннан тыш КФУ студентлары Казан данын яклап чыгыш ясый торган башка университетларның бию коллективлары составында да үзләрен күрсәттеләр.

Фестивальнең иң катлаулы номинацияләренән берсе – «Хореография» буенча көч сынашу Казан федераль университетының «УНИКС» концертлар залында үтте. Бу КФУда көчле матди база булуына дәлил. Чөнки «Вокал»да команда 4 кешедән генә дә тора алса, биюләрдә катнашучыларның саны иң кимендә 35.

5 көн күп вакыт булып тоелса да, күз ачып йомганчы бер мизгелдә үтте дә китте. «Россия студентлар язы – 2016» фестиваленең җиңүчесе булып кабат Татарстан Республикасы Казан шәһәре танылды. Төбәк программасы буенча гран-прига Ханты-Манси автоном округы ия булса, икенче урынга – Санкт-Петербург һәм Приморье крае студентлары, ә өченчегә – Төмән, Кемерово өлкәсе һәм Удмуртия Республикасыннан килгән студентлар лаек дип табылды. 2017 елда студентлар язы Тула шәһәрендә үтәчәк!

Безнең Казаныбыз исә кояшлы май көннәрендә яшьлегенең чәчәк аткан чагында бирегә килгән студентларга онытылмас мизгелләр бүләк иткәндер дип ышанасы килә. Казанның тарту көче өйгә кайтып җиткәч үзен тагын да ныграк сиздерә башлаячак әле.

«Россия студентлар язы – 2016» ▶ **3500** студент | **74** төбәк | **5** көн иҗат | **63** студент КФУдан

ИЛЕБЕЗНЕҢ ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРЕННӘН ҖЫЕЛГАН СТУДЕНТЛАР БЕЛӘН БЕЗ ДӘ АРАЛАШТЫК.

• **Рустам Тхагабсар (Кубань дәүләт университеты):**

Безгә монда бик ошый, бары да матур. Кремльгә бардык, демонстрациядә катнаштык. Без Казанга кавказ халык биюләрен алып килдек. Вакыт бик тыгыз, репетицияләр, ныклап әзерләнү. Казан турында моңарчы да ишеткән идем. Күп дуслар, танышлар биредә булып, кызыксындырып сөйләгән иделәр.

• **Анастасия Булгакова (Төньяк Кавказ федераль университеты):**

Ставрополь – җилле шәһәр. Монда да андый көчле җилләр булыр дип уйламаган идем. Әмма мәһабәт биналарның матурлыгын берни дә боза алмый. Россия студентлар язы – һәрвакыт берләштерә торган бәйрәм ул.

• **Марина Янщенко (Курган өлкәсе, Шадрин дәүләт педагогик университеты):**

Казан – үзенчәлекле шәһәр. Биредә берничә мәдәниятнең үрелеп баруын тойдым. Барысы да яшьләр өчен уйлап эшләнгәне күренә, бөтен җир пөхтә, матур. Биредә беренче тапкыр гына булсам да, тагын киләчәкмен дип кайтып китәм.

• **Кокулий Георгий (Ставрополь дәүләт медицина университеты):**

Без үзебезнең вокаль ансамблебез белән килдек. Казан безне җылы каршы алды. Биредә халык бик кунакчыл икән. Бик зур рәхмәт! Казан – искиткеч шәһәр, инфраструктура нык үсеш алган. Бигрәк тә социаль реклама таң калдырды!.. Танылган ризык – чәк-чәктән авыз иттек. Бездә ясалганыннан нык аерыла.

• **Юлия Иванова (Ульян дәүләт техник университеты):**

Казан – текә шәһәр. Россия студентлар язында мин беренче тапкыр гына, минем өчен бу зур үсеш, яңа дуслар табу мөмкинлеге. Ошап бетмәгән яклары да бар, әлбәттә. Атташелар берни дә белми, ярдәм итмиләр. Икенчедән, без шәһәрдән еракта урнашкан «Регина»да яшәдек. Автобуслар, урыннар буенча да конфликтлар булды. Ә гомумән алганда, яхшы ашаталар, көн бик бай үтә, тик утырырга вакыт юк.





Россия студентлар язы көннәрендә КФУ бик күп танылган шәхесләрне кабул итте: Чехов исемендәге Мәскәү художество театры режиссеры **Николай Скорик**, Дөньякүләм аренада танылып өлгергән хореограф **Марио Фарелли**, режиссер, продюсер һәм сценарист **Феликс Михайлов** һ.б..



Актер **Виталий Гогунский** Казанны Одессага охшаткан икән. Виталий әйтүенчә, биредә ачык күңелле, көләч йөзле һәм бик ягымлы кешеләр яши. Моннан тыш актерны КФУның мәһабәт биналары, әзерлекле базасы һәм студентлар өчен бөтен мөмкинлекләр дә булуы таң калдырган.




• Никита Тохтасинов, Влад Гордейко һәм Наталья Рузняева фотолары

# «ЛОБАЧЕВКА»НЫҢ ЯШӘЕШЕ

**Раил САДРЕТДИНОВ**

27 МАЙ – РОССИЯДӘ КИТАПХАНӘ (КИТАПХАНӘЧЕЛӘР) КӨНЕ. УЛ 1995 ЕЛДА РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ПРЕЗИДЕНТЫ Б.Н.ЕЛЬЦИН УКАЗЫ БЕЛӘН ГАМӘЛГӘ КЕРТЕЛӘ.

КФУның Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе – Россиядә борынгы һәм эре китапханәләрнең берсе. Ул Казан университеты белән бер үк вакытта – 1804 елда оештырыла. 1806 елдан, беренче китапханәче итеп Казан университеты профессоры М.Л.Староль билгеләнгәннән алып бүгенгә кадәр, эшләп килә һәм эре фәнни үзәкләрдән санала. 1932 елда китапханәгә фәнни статус, ә 1953 елда Н.И.Лобачевский исеме бирелә. Үз заманында китапханәгә Н.И.Лобачевский, К.К.Клаус, Н.Н.Зинин, А.М.Бутлеров, А.Е.Арбузов, Н.Ф.Катанов кебек күп галимнәр, язучылардан Л.Н.Толстой, П.И.Мельников-Печерский, композитор М.А.Балакирев, революционер В.И.Ульянов-Ленин h.б. бик күп атаклы шәхесләр йөри.

Узган гасыр студентлар буыны өчен китапханә китаплар тезелгән стеллаж, китап кыштырдавы белән хәтердәдер. Имтихан, рефератлар өчен кирәкле мәгълүмат ихтыяҗын алар китапханәләрдә тутыра торган була. Бүгенге студентларны курс эше, реферат өчен генә китапханәләргә җибәреп булмый. Гугл, яндекс, электрон китапханә – барысы да учыбызга сыйган смартфонда. Хәер, бу уңайдан безнең «Лобачевка»да заманадан артта калмый. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәне «ВКонтакте» социаль челтәрендә дә очратырга мөмкин. Төркем адресы: *https://vk.com/club104625425*. Моннан тыш, 6 миллион фондның бер миллионын электрон каталогта табарга мөмкин. Бу исә, өйдә компьютер каршыннан тормыйча да, КФУ китапханәсеннән кирәкле китапка заказ бирергә мөмкин дигән сүз. Аннан ул китапны бернинди чиратсыз билгеләнгән сәгатькә китапханәдән килеп алырга була. Кыскасы, вакыт әрәм итеп, баш катырып, каталоглар актарып утырырга кирәкми. Шулай ук башка китапханә фондларында булган мәгълүматны соратып алырга да була. Китапханә төрле чит ил һәм Россиянең башка китапханәләренә керү, алардан файдалану мөмкинлеген дә бирә, үз электрон коллекциясен тулыландыру өстендә эшли.



• **Линар Закиров, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты аспиранты:**

Китапханәләргә сирәк йөрим. Кирәкле әсәрне, фәнни хезмәтне Интернеттан эзләп табам. Әмма аспирантурада укып, диссертация язарга туры килгәнгә, китапханәгә сукмак салмыйча булмас. Чөнки миңа кирәкле, ягъни юнәлешем буенча хезмәтләр «челтәр»дә бик аз, ә аларның үзебезнең университет китапханәсендә күп икәнлеген беләм. Эш буенча соңгы елларда авыл җирләрендә салынган мәдәният йортларындагы китапханәләргә дә сугылырга туры килә, читтән караганда, шартлары яхшы, тик кайберләрендә интернет булмау кызганыч. Кайсы гына өлкәне алсаң да, электрон алгарышка уңай карыйм, чөнки ул бүгенге заманда иң җитенкерәмәгән әйбер – вакытны азмы-күпме янда калдыру мөмкинлеге бирә.

• **Айсылу Гаффарова, Инженерия институтының 4 курс студенты:**

Китаплар укырга яратам, бигрәк тә кәгазь вариантын. Шуңа күрә, китапханәгә керсәм, озак кына аннан чыга алмыйм. Казанда ешрак Мәүлетов урамында урнашкан 13 нче китапханәгә йөрим. КФУ китапханәләрендә барган үзгәрешләргә карашым уңай, минемчә, ул эзләргә, вакытны янга калдырырга зур мөмкинлек. Гомумән, китап уку модага керә, файдалы һәм мавыктыргыч. Мөмкинлекләр күп, бары теләк кенә кирәк!

• **Алсу Сәлахова, Л.Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының 3 курс студенты:**

Китапханәгә еш йөрим, чөнки сайлаган белгечлегем – татар теле һәм әдәбияты, журналистика. Институтыбыз китапханәсенә, милли китапханәгә һәм үзебезнең авыл китапханәләренә йөрим. Лобачевский исемендәге китапханәдә тудырылган электрон мөмкинлекләрдән файдаланмыйм.



# НЫКЛЫ АДЫМ БЕЛӘН КИЛӘЧӘККӘ

**Фәнзия НУРУЛЛИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

ТОРМЫШКА АЯК БАСУЧЫ ЯШЬЛӘРГӘ МӨМКИНЛЕГЕ, ТАЛАНТЫ, ТЕЛӘГЕНӘ ТУРЫ КИЛЕРЛЕК ИТЕП ҺӨНӘР САЙЛАРГА БУЛЫШУ, ЮНӘЛЕШ БИРҮ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА ГАИЛӘДӘН БАШЛАНСА, ИКЕНЧЕ ЧИРАТТА, ЮНӘЛЕШ БИРҮЧЕ БУЛАРАК, УКУ ЙОРТЫ, ОСТАЗЛАР ТОРА.

Дөрес сайланмаган һөнәр аркасында кешенең бөтен киләчәк тормышы бозылырга мөмкин. Җан ярат-кан хезмәт — бәхет бит ул. Элегрәк балалар космонавт, очучы, укытучы, инженер булырга хыялланалар иде. Заманалар тамырдан үзгәрде шул. Хәзер һәрберебез икътисадчы, юрист һөнәренә кызыга. Әлеге язмамның герое **Алсу Зинурова** да, мәктәпне тәмамлагач, икътисадчы булу теләге белән Казанга килә, Кооперация институтына керү бәхетенә ирешә. Күпмедер вакыт узгач, тынгысыз, бер урында таптанып торырга яратмавы нәтиҗәсендә, ул Казан федераль университетына журналист белгечлеген дә алырга уйлый. Тырышлыгы, оптимист рухлы булуы аңа уңыш арты уңыш китерә. Хыялларын чынга ашыру максатыннан бер генә минутка да читкә китми Алсу, гел хәрәкәттә, яңалык эзләүдә. Журналист белгечлеге шуны таләп итә дә инде. Студент кына булуына да карамастан, Алсу үзен бөтен яклап сынарга өлгерә. Чаллы шәһәрендә шәхси ипи пешерү цехын булдыру, Казанда фотостудия ачуы зур батырлык таләп итә. Япь-яшь студент кызның моңа курыкмыйча алынуы сокланырлык һәм үрнәк вакыйга. Мондый зур җаваплылык сораган эшкә бик сирәкләр генә алына. Ә Алсу Зинурова өчен кысалар юк, теләгәнен чынга ашыру, зур киртәләр аша курыкмыйча үтеп чыгу — аның яшәү рәвеше. «Студент еллары шундый вакыт бит инде ул, үзеңнең кайсы өлкәдә күбрәк белемле, сәләтле икәнеңне ачыклар өчен бирелгән мөмкинлек итеп кабул итәм мин аны. Күңелем теләгән өлкәдә курыкмыйча, кайнап каласым килә. Әлбәттә, киләчәктә шушы һөнәрләр арасыннан берсен сайларга туры киләчәк, тик хәзер сыналып, күп киртәләрне җиңеп яшәр вакытым», — дигән фикерләре белән уртаклашты Алсу.

Ныклы адымнар белән киләчәккә курыкмыйча атлаучы шундый яшьләребез күбрәк булсын, Алсуның эшләре киләчәктә дә авырлыкларсыз, җиңел генә барсын дигән теләктә калам.

# ӨЛКӘН СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ КЕМ БУЛЫРГА ХЫЯЛЛАНА?

ӘЛЕГЕ СОРАУНЫ КАЗАННЫҢ ИНГЛИЗ ТЕЛЕН ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНҮЧЕ 9нчы САНЛЫ МӘКТӘПНЕҢ ӨЛКӘН СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНА БИРДЕК.





Сораштырулар нәтиҗәсе буенча бары 3 кеше генә дәрәҗәле Мәскәү вузлары турында хыяллана. Санкт-Петербург университетына керү теләге белән унынчы сыйныфтан 4, унберенче сыйныфтан 2 укучы яна, аларның барысы да кызлар.

Казан университетларына килгәндә, булачак абитуриентлар саны буенча беренчелектә КФУ тора. Сораштырылган 34 кеше документларын шушы уку йортына бирергә нияте. Техник вузларга — КГАСУ, КНИТУ-КХТИ, КНИТУ-КАИ — барлыгы 28 укучы керергә уйлый. Егетләр, аеруча, физика-химия, гамәли информатика, югары компьютер технологияләрен өйрәнү белән бәйле белгечлек, университетларны үз итәләр. Бу исемлеккә шулай ук КФУның финанс һәм икътисад факультетлары керә. Кызлар исә лингвистика, филология факультетларын, «журналистика», «халыкара мөнәсәбәтләр», «кунакханә эше» белгечлекләрен якын итә. Шулай ук 10 абитуриент КГМУда дәвалау эше һәм стоматология юнәлешләре буенча китәргә исәпли. Егетләр һәм кызлар арасында архитектор, дизайнер, инженер, юрист, адвокат, программист, бухгалтер кебек һөнәрләр популяр.

**Татпресса.ру сайтыннан алынды.**



СТУДЕНТЛАР ҺӘРВАКЫТ ХӘРӘКӘТТӘ, КАЯДЫР АШЫГАЛАР, ЧАБАЛАР. АШЫГЫП ТУГАН ЯКЛАРЫНА КАЙТАЛАР, ЙӨГЕРЕП КИРЕ ШӘҺӘРГӘ КИЛӘЛӘР.

# Ашыгып ашка пешмә яки 150 сумга яшәп буламы?

**Алсу ЗИНУРОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Шул ритмга иялəшепме, авылдан шәһәргә килгәндә, рюкзагым онытылып калган. Зур сумка – янымда, күчтәнәчләр белән пакет та кулда, тик рюкзак кына юк, авылда калган. Аның юклыгы ярты юлга җиткәч кенә искә төште. Паспорт, машина йөртү таныклыгы, студент билетларым, зачетка, акча янчыгым, проездной, ачкычлар, флеш-карталар, фотоаппаратым – барысы да шул бер рюкзакта калды бит…

Беренче биш минутта паникага чумдым да, утыра торгач тынычландым тагын. Ярый, документларсыз яшәп тора алырмын, ә менә акчасыз… Карый торгач, кесәдән 150 сум акча килеп чыкты…

Автобуста юл йөрү 25 сум икән… Проездной белән йөргәч, элек игътибар биргәнем дә булмаган. Казанга килүгә, беренче 25 тәңкә автобуска китте. Ни хикмәт, икенче тапкыр автобуста баруым бушка булды: кондуктор әллә күрмәде шунда… Әлбәттә, болай эшләргә ярамый инде, әмма кесә ягы такыр булгач, мин авыз да ачмадым.

…Кибет янынnан узып барышым. Гадәттә, кереп, ике сумка азык-төлек күтәреп чыга идем. Бу юлы кибет ягына борылып та карамадым. Документлар кирәкмәс дигән идем дә, бик тиз кирәге чыкты. Үзең белән паспорт күчермәсен йөртергә кирәклегенә инандым. Гомумән, барлык документыңның да күчермәсен булдыру әйбәт эш икән.

Дус-туганнан бурычка сорамыйм, акча беткәнчегә чаклы яшәп карыйм әле дип, үземә сүз биргән идем. Шуннан соң өйдә моңарчы күзгә чалынмаган ашамлыкларны күрә башладым – шкафлар буш түгел икән, ярмасы-токмачы да, башкасы да бар икән бит. Аш плитәсе янында да ешрак басып тора башладым. Кибеттән ярымфабрикат яки әзер аш алып кайтканчы, үзең пешерәсең – тәмле дә, арзан да. Күбрәк җәяү йөрим, кибетләрне читләтеп узам. Бер яктан, ярый әле һава яхшы, җылы вакыт дип куанам – 30 градуслы салкында укырга җәяү йөреп булмас иде, мөгаен. Кирәк булганда, очрашуларны яшәгән җиргә якын билгели башладым. Тагын бер уңай ягы: алай иткәч, очрашуларга соңга да калынмый икән.

Эх дигәнче, биш көн узып та китте. Шул вакыт эчендә минем 150 сумнан 25 сум калды да әле. Мондый хәлдән соң инде игътибарлырак булырга өйрәндем: авылдан киткәндә, бар аласы әйберләрне кат-кат тикшереп чыгам. Шулай ул, бер авызың пешсә – өреп кабасың диләрме әле?!

25 МАЙ – РОССИЯДӘ ФИЛОЛОГЛАР КӨНЕ БУЛАРАК БИЛГЕЛӘП ҮТЕЛӘ.

# Филологлар тормышыннан

Казан федераль университетының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлеге укытучылары, студент-аспирантларының һөнәри бәйрәме дигән сүз бу. Филолог диюгә, иң беренче чиратта күз алдына күзлекле, кулына күп китаплар тоткан кеше килеп баса. Филология кемнәр өчендер күңелсез шөгыль булып тоелса да, үз гомерләрен аңа багышлаган студентлар исә күңелле яши. Алар тормышыннан мәзәкләр тәкъдим итәбез.

Борынгы әдәбияттан имтихан биргәндә.

**Студент:** Сәйфелмөлек белән Бәдигылҗәмал бик күп авырлыклардан соң бергә калалар.

**Хатыйп абый:** Шуның белән бетәме?

**Студент:** Борынгы заман әдәбиятында язучы мәхәббәтне һәрчак идеаль итеп сурәтли…

**Хатыйп абый:** Ә син андый мәхәббәткә ышанасыңмы?

**Студент:** Әлбәттә!!! Бер-берсен яратучы ярлар,үзләренең мәхәббәтләре өчен барлык авырлыкларны үтеп, бергә калу бәхетләренә ирешәләр…

**Хатыйп абый:** Бигрәк илһамланып сөйлисең, син үзең дә шундый хисләр кичерәсеңме әллә?

**Студент:** Әсәрләр илһамландыра.

**Хатыйп абый:** Вәәәәт сиңа, судан коры чыга беләәәә…

Студент кыз «Ялкын» журналы баш мөхәррире, танылган яшь шагыйрә Йолдыз Миңнуллинага зарлана:

- Язып булмый, Йолдыз апа. Язсам да, нинди дер коры җөмләләр килә дә чыга.

- Ә син коры итеп яз да, аннан юешләп чык!

Диалектология фәненнән имтиханга әзерләнү. Каршыда бүлмәдәшем Зөһрә тырыша-тырмаша урта диалектның сөйләшләрен ятлый:

- Әстерхан, Бастан, Бәрәңге…Алияяя.. Богрыслан, Бөре, Златоуст… Ничек ятларгаааа…

**Мәзәкләр «Раушан» студентлар газетасыннан алынды.**

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: Р.Р.Садретдинов, А.А.Абдрахманова
Корректор - Р.Ә.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru
Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00, 26.05.2016. «Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.